**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22,chishma@tatar.ru

# Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы КАРАРЫ

2015 елның «12» февраленнән № 41-241

## «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы каршында Яшьләр парламентын төзү турында»

Татарстан Республикасы Президенты Р. Н. Миңнехановның 2014 елның 27 декабрендәге пр-344 боерыгын үтәү йөзеннән һәм Яңа Чишмә муниципаль районы Советының яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен җайга салу, Яңа Чишмә районында яшьләр проблемаларын чишү буенча тәкъдимнәр әзерләү өлкәсендәге эшчәнлегенә ярдәм итү максатыннан, Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Яңа Чишмә муниципаль районы Советы каршындагы Яшьләр парламенты Советының санын һәм составын расларга. (2 нче кушымта)

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль сәясәт буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

5. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

**Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Советының
2015 елның «12» февралендәге
41-241 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Яңа Чишмә муниципаль районы Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Район Советы каршындагы Яшьләр парламенты (алга таба – Яшьләр парламенты) яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен законнар белән җайга салу, яшьләр проблемаларын хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләү, яшьләр өчен шартлар тудыру, закон чыгару эшчәнлеге күнекмәләрен үзләштерүдә район Советы эшчәнлегенә ярдәм итү максатыннан оештырыла.
2. Яшьләр парламенты Совет каршындагы киңәшмә һәм консультатив орган булып тора һәм әлеге Нигезләмә һәм яшьләр парламенты регламенты нигезендә үз эшчәнлеген иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыра.
3. Яшьләр парламенты 5 елга формалаша.

## II. Яшьләр парламентының төп бурычлары

1. Яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы карарлар кабул итүне әзерләү буенча район закон чыгару җыелышлары комиссияләре эшчәнлегендә катнашу.
2. Район Советы карарлары проектларын эшләгәндә яшь гражданнарның инициативаларын тәкъдим итүдә булышлык күрсәтү.
3. Яшьләрнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре өлкәсендә законнарны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү.
4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендәге законнарны гамәлгә ашыруга җәмәгать контролен гамәлгә ашыру.
5. Яшьләр даирәсендә яшьләрнең хокукый культурасын күтәрүгә һәм актив гражданлык позициясен формалаштыруга юнәлдерелгән агарту һәм аңлату эшләре алып бару.

## III. Яшьләр парламенты составы һәм тәртибе

1. Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә яшәүче, яшьләр парламенты составына сайланган вакытта 30 яшькә кадәрге Россия Федерациясе гражданнары Яшьләр парламенты әгъзалары була ала.
2. Яшьләр парламенты Татарстан Республикасының республика яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең район вәкиллекләреннән, Татарстан Республикасында

Гомумроссия яшьләр иҗтимагый оешмалары бүлекләреннән, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советында тәкъдим ителгән сәяси партияләрдән, шулай ук «ПолитЗавод» проектының муниципаль этабында катнашучылардан (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасы составына кермәгән) тора.

3. 2 пунктта күрсәтелгән оешмалар үз утырышларында берәр вәкилне яшьләр парламентына сайлап алалар һәм тиешле карарны парламент Советына юллыйлар.
4. Яшьләр парламенты Советы әлеге парламент әгъзаларының санын билгели һәм вәкаләтләрен раслый.
5. Яшьләр парламенты рәисе итеп Яңа Чишмә муниципаль районыннан сайланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасы әгъзасы билгеләнә.

## IV. Яшьләр парламенты эшен оештыру

1. Яшьләр парламентының беренче утырышы элеккеге чакырылыш Яшьләр парламенты Советы тәкъдиме буенча чакырыла, шулай ук беренче утырыш көнен билгели, аңа Яшьләр парламенты әгъзаларын чакыра, чакырылганнар исемлеген һәм алып бару тәртибен билгели торган Яңа Чишмә муниципаль районының закон чыгару җыелышы тарафыннан чакырыла.
2. Яшьләр парламентының беренче утырышын әлеге парламент рәисе ача.
3. Беренче утырышта Яшьләр парламенты әгъзалары ачык тавыш бирү һәм гади күпчелек белән рәиснең ике урынбасарын, җаваплы секретарьне сайлыйлар, Яшьләр парламентының санлы составын билгелиләр һәм аның әгъзаларын сайлыйлар, комиссияләр төзиләр.
4. Яшьләр парламенты утырышы, әгәр анда яшьләр парламенты әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы була.
5. Яшьләр парламенты үз эшчәнлегенең юнәлешләре буенча тәкъдимнәр әзерли, кабул итә һәм аларны җирле үзидарә органнарына җибәрә.
6. Яшьләр парламенты карарлары һәм тәкъдимнәре Яшьләр парламенты әгъзаларының билгеләнгән саныннан күпчелеге алар өчен тавыш бирсә кабул ителгән дип санала.
7. Яшьләр парламенты советын рәис җитәкли, аның вәкаләтләре яшьләр парламенты регламенты белән билгеләнә.
8. Яшьләр парламенты Советы:

- Яшьләр парламенты һәм аның комиссияләре эшен оештыра һәм координацияли;
- Яшьләр парламентының эш регламентын эшли;
- Яшьләр парламентының чираттагы елга эш планнарын эшли һәм аларны Яшьләр парламентына раслауга тәкъдим итә;
- Яшьләр парламенты регламенты нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

9. Яшьләр парламенты Советы тәкъдиме буенча яшьләр парламенты әгъзалары муниципаль район Советы депутатларына җәмәгать башлангычларында ярдәмчеләр сыйфатында тәкъдим ителергә мөмкин.
10. Яшьләр парламенты комиссияләре эшен оештыра һәм яшьләр парламенты утырышларында карау өчен үз функцияләренә ярашлы тәкъдимнәр һәм карарлар проектларын әзерли.

11. Яшьләр парламенты эшендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы, Дәүләт Советы депутатлары, шулай ук чакыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләре, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының вәкиллекле органнары депутатлары, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары вәкилләре, Татарстан Республикасы территориясендә эш итүче сәяси партияләр һәм иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлар катнаша ала.
12. Яшьләр парламенты утырышларын оештыру-техник тәэмин итү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районыа
Советының
2015 елның «12» февралендәге
41-241 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Яңа Чишмә муниципаль район Советы каршындагы
Яшьләр парламенты Советы составы**

Иванова И. И. - Яңа Чишмә муниципаль районының яшьләр парламенты рәисе

Шолгина Е. С – - Яңа Чишмә муниципаль районының яшьләр парламенты рәисе урынбасары.

Холина Е. В. - Яңа Чишмә муниципаль районының яшьләр парламенты секретариаты.

Абрамов А. В. - Яңа Чишмә муниципаль районының спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше комиссиясе рәисе.

О. А. Юдинцева-Яңа Чишмә муниципаль районының патриотик тәрбия комиссиясе рәисе.

Е. П. Янова-Яңа Чишмә муниципаль районының авыл яшьләре белән эшләү буенча рәисе.

Мартышова С. В. - Яңа Чишмә муниципаль районының яшьләр парламенты әгъзасы.

Богомолова А. Л. - Яңа Чишмә муниципаль районының яшьләр парламенты әгъзасы.

Нуртдинова Г.М. – - Яңа Чишмә муниципаль районының яшьләр парламенты әгъзасы.